СӘБӘП НИДӘ?
Авылларда, хуҗалыкларда мал табиблары җитми
> 2

КОРТ ТҮГЕЛ, ИТ!
Министр микротерлекчелекне үстерү турында уйланырга тәкъдим итә
> 3



СИНЕ КӨТӘМ
Солдат хатыны нинди уй-хисләр белән яши?
> 4

ҮЗЕМ КҮРДЕМ
Аз санлы халык саналган саамнарның тарихи ватанына сәяхәт
> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 22 (28989) | Сишәмбе | 14 февраль | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

ЙОРТ САЛУНЫҢ НИЕ БАР

Халык шәһәрләрдә таш йортларда «бикләнеп» беткәч, илдә агачның кадере турында искә төшергәннәр. Россия Президенты Владимир Путин әлеге төр материалдан йорт җиткерергә теләүчеләргә өстәмә ярдәм чаралары булдырырга кушкан. Алай гына да түгел, илдә агачтан төзелгән тәүге күпфатирлы йортта фатирлар сата башлаганнар әнә. Ташмы, агачмы? Бу сораугa «ВТ» хәбәрчесе ачыклык кертергә тырышты.

vk.com

Рамил Насыйров узган ел Биектау районының Шигали бистәсендә агач йорт җиткергән.

– Мин үзем – балта остасы, – ди ул. – Агачның кадерен бик яхшы беләм. Кирпечтән салынган йортка киткән чыгымнар үзен акламый. Обой ябыштырганчы, аны ничә кат тигезләп, ничә кат агартырга гына кирәк бит. Агач йортны өч еллап төзедек. Башта ике катлы төзелешне түбә астына керттек, аннары акрынлап бүлмәләрен эшләдек. Йорт эчендәге төзелеш эшләрен исәпкә алмыйча, дүрт бүлмәсе һәм мунчасы булган 140 квадрат метрлы торак якынча 15 миллион сумга төште. Моңа барлык чыгымнар да кермәгән, билгеле. Туганнарым да күп ярдәм итте. Әзер кирпеч йорт сатып алган булсам, күпкә очсызрак булыр иде. Тик таш диварлардан тәмам туйдым. Агач йортка килеп керүгә, сулыш киңәя, кәеф күтәрелә. Матурлык ягыннан да агачның бизәге кабатланмый.

Киләчәктә Рамил кебек фикер йөртүчеләр тагын да күбәеп китмәгәе. Ил күләмендә урман сәнәгатен үстерүгә багышланган киңәшмәдә Илбашы Владимир Путин агачтан йорт салырга теләүчеләргә ярдәм чараларын арттырырга кушты. Президент әйтүенчә, бүгенге санкция шартларында әлеге тармак шактый катлаулы хәлдә калды.

– Безнең компанияләр өчен Европа базарлары ябылды. Бу исә җитештерү күрсәткечләре кимүгә китерде. Безгә ил эчендә агач сәнәгатенә карата кызыксынуны арттырырга кирәк, – диде Россия Президенты.

Эш юнәлешләре дә билгеле инде. Мәсәлән, ипотекага агачтан төзелгән йорт сатып алырга теләүчеләргә ташламалар гамәлгә кертмәкчеләр. Алдан түләгән акча «җилгә очмасын» өчен, күпфатирлы йортлар төзелешендәге кебек үк, эскроу-счетлар булдырырга да тәкъдим иткәннәр. Ягъни төзелеш оешмасына акча эш беткәннән соң гына күчәчәк, аңа кадәр исә банкта сакланачак. Төзүчеләргә ярдәм чарасы турында да искә төшергәннәр. Билгеле булганча, «агач ипотекасы» ташламалы программасы 2018 елдан бирле гамәлдә. Аның нигезендә, ил Хөкүмәте агач йорт сатып алуга ташламаны субсидияли. Моның өчен ел саен кимендә 300 миллион сум акча бүлеп бирү күздә тотыла. Әлеге мөмкинлектән файдалану өчен, төзүчеләргә берничә шартны үтәргә кирәк. Шул исәптән, әзер йортның бәясе 3,5 миллион сумнан артмаска тиеш.

Владимир Путин авылларда фельдшер-акушерлык пунктлары, балалар бакчалары, мәдәният йортлары кебек социаль әһәмияткә ия булган төзелешләрдә дә агач материалларны кулланырга киңәш иткән. Киләчәктә авария хәлендәге торакта яшәүчеләр дә агачтан төзелгән күпфатирлы йортларга күченә башламагае. Бу да – Президент тәкъдиме. Вологда өлкәсендә шундый тәүге торакта фатирлар сата башлаганнар инде. Әйтүләренә караганда, CLT-панель, ягъни тактаны үзара аркылыга катткат ябыштырып эшләнгән блоклардан төзелгән мондый йортларга 50 ел бернинди капиталь ремонт кирәкми. Дөрес, моны беркем дә тикшереп карамаган. Яңа технология үзе дә моннан күпкә «яшьрәк» әле.

Тик эрләмәгән, сукмаган, дип кул селтәргә ашыкмагыз. Татарстанда CLT-панельдән йорт салу белән инде ике еллап шөгыльләнәбез, ди Лаеш районында урнашкан төзелеш оешмасы директоры Илдар Гайнуллин.

– Чит илдә мондый технология күптән кулланыла, – ди ул. – Норвегиядә, мәсәлән, агачтан 18 катлы йортлар төзиләр. Әлеге материал бик чыдам, мондый йортларның нигезе «утыра» дип тә борчыласы юк. Өстәвенә CLT-панель җылылыкны өч тапкыр яхшырак саклый. Таш диварны күз алдына китерегез: ике кирпеч арасындагы синтетик җылыткычның куллану вакыты нибары өч ел. Димәк, өч елдан соң аның бернинди файдасы калмый. Ә агачка берни булмый. Әзер панельләрдән йорт салу өчен бер көн вакыт җитә. Мондый төзелеш кыйммәтрәк, билгеле. Тәрәзә, ишек, нигезне дә исәпкә алып, әзер торакның бер квадрат метры уртача 100 мең сумнан башлана. Сатып алучылар җитәрлек. Агач өйгә күбрәк үз сәламәтлеге турында кайгыртучылар өстенлек бирә.

Саннарга килгәндә, узган ел республикада яшәүчеләр 15 меңнән артык шәхси йорт төзегән. Росреестрның Татарстан буенча идарәсе мәгълүматларына караганда, халык күбрәк «таш капчык»ларга өстенлек бирә. Былтыр кадастр исәбенә куелган шәхси йортларның 7 меңнән артыгын кирпечтән салганнар. Идарә җитәкчесе урынбасары Лилия Борһанова сүзләренә караганда, соңгы арада агачка өстенлек бирүчеләр саны арта башлаган. Былтыр 2 меңнән артык милек хуҗасы агач йортта өй туе үткәргән әнә. Республикада яшәүчеләр арасында төзелеш өчен иң сирәк кулланылучы материаллар – таш (34 йорт) һәм бетон панель (5 йорт). «Былтыр кадастр исәбенә куелган барлык йортларның яртысы – бер катлы төзелешләр. Ике катлы йортлар – 46 процент, ә өч катлылары 4 процент тәшкил итә», – ди Лилия Борһанова.

Эльвира ВӘЛИЕВА

«Дом.РФ» аналитика үзәге җитәкчесе Екатерина ВЛАСОВА:
– Былтыр Идел буе федераль округында 83 мең шәхси торак йорт төзелгән. Аларның гомуми мәйданы 12 миллион квадрат метр тәшкил иткән. Алдагы ел белән чагыштырганда, бу – 11 процентка күбрәк. Шәхси йортларның иң күбесе – Татарстанда. Икенче урында – Чувашия Республикасы. Оренбург өлкәсе исә – өченче.

Без – дүртенче

Узган ел нәтиҗәләре буенча Татарстан төбәкләрдәге тормыш сыйфаты буенча дүртенче урынга чыккан. Республика бары тик Мәскәү, Петербург һәм Мәскәү өлкәсеннән генә калыша. «РИА Новости» хәбәренә караганда, рейтингның беренче җиде урыны 2021 елдан бирле үзгәрешсез калып килә. Бишенче урында – Краснодар крае. Белгород өлкәсе – алтынчы, Ленинград өлкәсе – җиденче. Шунысы кызык: Татарстан, урынын үзгәртмәсә дә, рейтингтагы баллы артып, 72,113кә кадәр җиткән (2021 елда – 69,361 балл).

Узган елда Еврей автономияле өлкәсе, Ингушетия һәм Тыва иң ахыргы урыннарны (83–85 нче) алган. Яңа төбәкләр – Донецк, Луганск Халык Республикалары, Запорожье һәм Херсон өлкәләре рейтингта катнашмаган. Төбәкләрне бәяләү өчен тормыш шартларын, социаль өлкәдәге вазгыятьне билгеләүче 67 күрсәткеч алынган. Шулар нигезендә рейтинг баллы исәпләп чыгарылган.

Хәләл булыр

Россиядә берничә ел эчендә хәләл кунакханәләр пәйда булырга мөмкин. «Известия» хәбәренә караганда, әлегә илдә шәригать кануннарына туры килердәй отель юк. Шуңа күрә туристлар арасында диниләр күп түгел. Хәләл кунакханәләр исә чит илләрдән килүче кунаклар, шулай ук ил эчендәге сәяхәтчеләр санын арттыруга ярдәм итәр дип көтелә.

Әйтергә кирәк, башка илләрдә мондый кунакханәләр инде байтактан эшләп килә. Гадәттә кунакларга хәләл ризыклар, намаз бүлмәләре һәм тәсбихләр тәкъдим ителә. Шулай ук кунакханә эчендә кеше, хайван сурәтләре юк. Юыну бүлмәләрендәге шампунь-гельләр составына терлек майлары, спирт кушылмаган.

Сүз уңаеннан, 2019 ел азагында Татарстанда 5 шифаханәне хәләл стандарты буенча сертификатлаштыру башланган. Болар – Чаллының – «Радуга», Әлмәт районының – «Ян», Яшел Үзән шәһәренең – «Дельфин», Чаллының – «Жемчужина», Менделеевск районы Ижевка авылының «Шифалы су – Ижминводы» шифаханәләре.

Чир чигенми

Татарстанда коронавирус йоктыручылар саны һаман арта. Стопкоронавирус.рф порталы мәгълүматларына караганда, соңгы тәүлектә 104 кешенең чир иярткүе ачыкланган (узган тәүлектә – 100 кеше). 24 кеше (алдагы көнне – 39) хастаханәгә озатылган. Пандемия башланганнан бирле республикада барлыгы 196325 кеше чирләгән. Бездә COVID-19 инфекциясеннән вафат булучыларның гомуми саны, элеккечә үк, 2010 кеше. Соңгы тапкыр коронавирустан үлү очрагы турында 20 гыйнварда хәбәр ителде.

Тулаем Россия буенча бер көн эчендә вирус йоктыручылар саны 1006 кешегә арткан. 6484е, савыгып, аягына баскан. 19608 сырхау хастаханәгә озатылган. 30 кешенең чирдән вафат булуы теркәлгән.

Салкын килә

Бу атнада Татарстанда суыта. Гидрометеоүзәк мәгълүматларына караганда, һава температурасы төнлә 20 градуска кадәр төшәчәк. Алдагы көннәрдә аз гына кар-буран күзәтеләчәк. Чәршәмбе – 15 февральдә көндез –4…–9, төнлә –7…–12 градус көтелә. Пәнҗешәмбе – 16 февральдә көндезге сәгатьләрдә термометрның терекөмеш баганасы –2…–7, төнлә –9…–14 градус күрсәтәчәк.

Синоптикларның башлангыч фаразына караганда, җомга һәм шимбә – 17–18 февральдә урыны белән аз гына кар булырга мөмкин. Көндез һава температурасы –5…–10 градус чикләрендә тирбәләчәк. 17 февраль төнендә –9…–14, 18 февраль төнендә –15…–20 градуска кадәр суытачак.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Спорт кына түгел бу!

Замана ярышы

Тарихта – беренчесе, Казан өчен – өченчесе. Татарстан башкаласында «Фиджитал уеннар»ның өченче этабы узды. Бу ярышлар 2024 елда Казанда узачак «Киләчәк уеннары»на әзерлек буларак та оештырыла дисәк, ялгыш булмас. Уйнар алдыннан уйнап алдылар, кыскасы.

vk.com

Исегездә булса, «Фиджитал уеннар»ның беренче-икенче этабы узган елның көз-кыш айларында узды. 5–11 февраль көннәрендә кабат ярыштылар. Өч этапта 7 илдән 30лап команда көч сынашкан. Соңгысында 132 спортчы килгән иде. Алар биш төрле юнәлештә ярышты.

Шунысын да искәртик: «Фиджитал уеннар» күз күреп ияләнгән ярышлардан аерыла. Мондый ярышлар дигәндә, спортның классик төрләрен һәм киберспортны берләштергән уеннарны күзалларга кирәк. Алар чынбарлык һәм цифрлаштыруны берләштерә, спортчылардан техник, санлы (виртуаль), физик әзерлек таләп итә. Гади итеп әйтсәк, спортчы цифрлы дөньяда да, чынбарлыкта да ярыша, уйный. Әйтик, башта компьютер янына утырып, туп типсә, соңрак чын футбол кырына чыгып, осталык күрсәтә.

«Киләчәк уеннары» проекты җитәкчесе Игорь Столяров әйтүенчә, уеннарның гомуми приз фонды 6,5 млн сумны тәшкил иткән. Димәк, катнашучылар арасында көндәшлек тагын да зуррак булган.

– Уеннарның эчтәлеген үзгәртмәдек. Спорт аша кибератлет үзенең физик мөмкинлекләрен күрсәтә ала, ә компьютерда исә цифрлы өлкәдәге тәҗрибәсен сыный, – диде Игорь Столяров.

Татарстанның спорт министры Владимир Леонов аңлатканча, сынау ярышларын уздыру төп уеннар алдыннан нәтиҗә ясарга да мөмкинлек бирәчәк.

– Без быел барысын да сынап караячакбыз. Формат, объектлар, эчтәлек… Барысын да хәл итәчәкбез, – диде ул.

«Киләчәк уеннары»ның күзәтчелек советы әгъзасы Владимир Волошин сүзләренчә, Россия мондый уеннар уза торган беренче ил булып тарихка кереп калачак. «Күпләр уеннарның «туры эфир»ларына кушыла, Казандагы ярышларны үз күзләре белән килеп карый. Бу – киләчәк спортының стратегиясе. Минемчә, ул бөтен дөньяга таралачак», – дигән фикердә ул.

Бу юлы катнашучылар популяр компьютер уеннары (CS:GO, Warface һ.б.), лазертаг буенча көч сынашты. Волошинның уеннар концепциясе бөтен дөньяга таралачак дигән сүзләре кайчан чынга ашасын вакыт күрсәтер, анысы. Ә менә уеннарның җанатарлары бөтен дөнья буенча таралуы – бәхәссез.

Денис исемле егет Берлин шәһәрендә яши. Казандагы ярышларны онлайн күзәткән. «Шундый кәттә чемпионат! Оештыру – югары дәрәҗәдә! Бөтен нәрсә виртуаль һәм шул ук вакытта чын да кебек. Карау кызык», – диде ул. Аерым бер команда өчен җан атмаган, күбрәк мавыктыргыч шоу көттем, ди. Җанатарның күңеле булган.

Сүзгә-сүз

Сергей КОЛОДНИКОВ, Татарстанның Хисап палатасы аудиторы:

Социаль сораштыру күрсәткәнчә, авылларда кияүгә чыгу яшендәге кызлар аз. Анда 25 яшьтән алып 34 яшькә кадәрге ир-атларның саны хатын-кызлардан күбрәк. Бу яшь гаиләләр коруда проблемалар тудыра. Яшьләрнең авылдан китүенең бер сәбәбе әнә шул.

(Дәүләт Советының бюджет, салымнар һәм финанс комитеты һәм экспертлар советының уртак утырышында әйткән сүзләре)

РОССИЯДӘ – БӘХЕТ КҮРСӘТКЕЧЕ

«Aventica» агентлыгы Россиядә яшәүчеләрдән: «Сез үзегезне бәхетле итеп тоясызмы?» – дип сорашкан.



Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

ГАЛӘМНӘР СУГЫШЫ БАШЛАНЫРМЫ?

Үткән атна борчулы, тетрәндергеч, фаҗигале вакыйгаларга бай булды. Турбулентлыкта беренче урынны, әлбәттә, төрек фаҗигасе тота. Без, ихтимал, атна ахырына ул хакта күләмлерәк язма әзерләрбез әле, чөнки трагедия планетакүләм хаоска этәргеч бирүче зур факторга әйләнергә мөмкин. Бу язмада исә болганчыклыкның яңа бер симптомы турында сөйләшербез.

Үткән елларда Төньяк Америкадан сәер хәбәрләр яуды. АКШта һәм Канадада атмосферада сәер объектлар күзәтелде һәм бәреп төшерелде. Болары инде Кытай шарлары гына түгел, җитдирәк һәм куркынычрак. Бу юлларны язарга әзерләнгәндә, дүшәмбе таңы атар алдыннан, автор АКШтан һәм Кытайдан игезәк ике хәбәр алды. «АКШта, – дип хәбәр итә рәсми чыганакларның беренчесе, – F-16 истребителе Гурон күле өстендә 6 км биеклектә сигез почмаклы билгесез объектны бәреп төшерде. Инде өченче көн рәттән Төньяк Америка өстендә билгесез объектлар бәреп төшерелә».

Кытай хәбәрчеләре: «Кытай һава киңлекләрендә шулай ук билгесез объект күзәтелә, аны шулай ук бәреп төшерергә планлаштыралар. Объектны яр буе шәһәре Жичжао акваториясендә (Шаньдун провинциясе) күреп алдылар», – дигән яңалык юлладылар. Юк, юк, сез ялгыш аңлыйсыз, болар берсе дә сары матбугат хәбәрләре түгел, рәсми мәгълүмат. Ышанычлы чыганаклар. «Коммерсантъ»ның сайтын ачабыз да рәхәтләнеп укыйбыз: «…АКШ генералы Глен ван Херк Төньяк Америка өстендә бәреп төшерелгән объектларның чыгышлары белән Җирнеке булмавы ихтималын кире какмый». Сүзләр – Төньяк Америка Һава һөҗүменә каршы тору командованиесе җитәкчесенеке. Американың Fox News телеканалы (җитди һәм объектив хәбәрләр таратучы булып санала) шундый ук хәбәрне Конгресс вәкиле Джек Бергман авызыннан тарата. «Российская газета» да язды ул хакта.

«Ватаным Татарстан» хәбәрчесе озакламый оча торган тәлинкәләр белән сугыш башланачагын 2021 елның декабрендә үк фаразлаган иде. Бернинди чит планета вәкилләре дә юк, әлбәттә. Җир тирәсендә аларның корабллары да әйләнеп йөрми. Әмма хәзерге технологияләр белән кешелек җәмгыятен ышанмастай нәрсәләргә ышандыру берни дә тормый», – дип яздык без ул мәкаләдә. Америка генераллары һәм аларның кытай коллегалары безнең шул фаразларны тормышка ашырырга азапланалар. Сүз бик зур һәм дәһшәтле сценарийның прологын сынап карау турында бара. Мин ул хакта киңрәк яза алыр идем, бердән, урын тар, икенчедән, кешеләр безне юләргә санаячак. Әмма вакыйгаларның болганчык чоңгылына ияреп кереп китәчәкләр алар. Галәмнәр сугышы театры сәхнәсе әйләнә башларга бераз вакыт бар дип саныйм.

Россиядә

СЕЗДӘН БАШКА БУЛМЫЙ, МӨҺАҖИРЛӘР

Россия Хөкүмәте икътисадый проблемаларны чишү белән мәшгуль бу көннәрдә. Үткән атнада валюта курслары югары күтәрелде. Бюджет өчен оптималь курс эзләү дәвам итә. Курс болайрак исәпләнәчәк: долларда күпме генә тормасын, нефтьнең барреле сумнарда 4500гә тигез булырга тиеш, ягъни «юралс» илле доллардан сатылса, Америка кәгазенең 90 сумнан йөрүе хәерле. Энергетика министрлыгы долларны гына түгел, «кара алтын» бәясен күтәрү өчен дә тырыша. Вице-премьер Новак илнең мартта нефть чыгаруны 500 мең баррельгә киметәчәген игълан итте инде. Мәскәү фикеренчә, бу адым җир мае бәясен югары чөяргә тиеш. Фараз акланса, доллар курсы күтәрелмәс, дип өметләнеп була. Федераль хөкүмәт Кытайның нефтькә ихтыяҗы 500 мең баррельгә, глобаль икътисадныкы 2 миллион 500 мең баррельгә үсәчәк дип ышана.

Хөкүмәт эре бизнестан ирекле рәвештә взнослар да таләп итә. Олигархлар үз теләкләре белән казнага 200 миллиард сум тапшырсыннар, ди. Тегеләре бик шатланмый инде, билгеле. «Известия» газетасы даруханәләрдә «Бисептол» һәм «Панадол» препаратлары юкка чыгуын хәбәр итә. Моңарчы дефицитта булган дарулар да киштәләргә кайтмады әле.

Проблемаларның шундый төене фонында компанияләр эшче куллар җитмәү дигән сызлавыктан интегә. «Понаехали» дигән тәкәббер сүзне читкә куеп, бизнес хөкүмәттән гастарбайтерларга таләпләрне киметүне үтенә. Уртаазиялеләр хәзер күбрәк килә башлаган, әмма ковидка кадәрге чордан калыша әле. Хөкүмәттә дә мәсьәләнең кискенлеген аңлыйлар. Өч Урта Азия республикасында – Таҗикстан, Кыргызстан, Үзбәкстанда мигрантларны юлга чыкканчы ук әзерләү үзәкләре ачу планлаштырыла. Дактилоскопия, фотога төшү, регистрация, медицина белешмәсе кебек мәшәкатьләрне булачак мөһаҗирләр үз илләрендә үк үтәргә тиеш булалар.   Таҗикстан белән шул хакта хөкүмәтара килешү 2023 елда ук имзаланыр дип көтелә. Тәкъдимнәр Үзбәкстан белән Кыргызстанга да ясалган.

Мөһаҗирләрдән башка алга бару һич мөмкин түгел. Бизнес та, чиновниклар да хәзер шул фикердә. Петербургта аларга теплица шартлары тудырырга да ризалар, чөнки ТКХ өлкәсендә эшче кулларга кытлык шулкадәр зур: җыештырылмаган урамнар икенче башкаланың визит карточкасына әверелеп бара. Анда урам себерүчегә – 49 мең сум, җыештыру техникасында эшләүчеләргә 77 мең сумга якын акча түләү, бушлай яшәү урыны тәкъдим итәләр. Эшмәкәрләр хокукын яклаучы Борис Титов эшкә патентны өч елга кадәр озайтуны сорый. Хезмәт хаклары ярыйсы гына инде: мультфильмдагыча: «Такая корова нужна самому», – дип әйтерлек. Әмма доллар чамасыз үсеп китсә, мигрантлар кызыкмаска да мөмкин.

КОТЛЫЙБЫЗ!

Җир асты катламнарының нефть бирүчәнлеген арттыру максатында акватермолиз катализаторларын эшләгән өчен техник фәннәр кандидаты, «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем бирү федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесе өлкән фәнни хезмәткәре **Мөхәммәтдинов** Ирек Изаил улына, Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә, яшь галимнәр өчен фән һәм инновацияләр өлкәсендә Россия Федерациясе Президенты премиясе билгеләнде һәм яшь галимнәр өчен фән һәм инновацияләр өлкәсендә **«Россия Федерациясе Президенты премиясе лауреаты»** дигән мактаулы исем бирелде.

РӘИС КӨНДӘЛЕГЕ

САКЛАРГА ҺӘМ ТАНЫТЫРГА

Кичә Казанда танылган опера җырчысы Федор Шаляпинны искә алдылар. Көн дәвамында башкалада аның тууына 150 тулуга багышланган чаралар узды. Шаляпин һәйкәленә чәчәк салудан соң, башкаланың Пушкин урамындагы унынчы йортта мәшһүр опера җырчысына истәлек тактасы ачылды. Тантанада Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов та катнашты.

– Рус мәдәнияте үсешенең тулы тулы бер чоры Шаляпин исеменә бәйле. Ул югары опера сәнгате үсешенә зур өлеш кертте. Ул тудырган сәхнә образлары өлгегә әверелде. Ул сәләтле актер, оста рәссам буларак та танылды. Шаляпин бөтен дөнья күләмендә танылган артист иде, – диде Рөстәм Миңнеханов. – Без бөек җырчыны хөрмәтлибез, хәтерлибез. Ел саен Шаляпин исемендәге опера фестивале уздырыла, башкаладагы бер урам аның исемен йөртә. Танылган якташыбызга Бауман урамында куелган һәйкәл дә шәһәрнең күренекле урынына әверелде. Бүген без ачкан истәлек тактасы – бөек Шаляпин иҗатына хөрмәтнең тагын бер үрнәге. Республикабыз мәдәнияте, тарихы һәм танылган шәхесләренең иҗатына битараф булмаган һәркемгә рәхмәт әйтәсем килә. Ул калдырган мәдәни мирасны саклау һәм популярлаштыру бик мөһим.

tatarstan.ru

Үсәсе дә үсәсе

Татарстан Рәисенең районнарга эш сәфәрләре дәвам итә. Бу юлы Рөстәм Миңнеханов Балык Бистәсенә барды. Республика Рәисенә агросәнәгать комплексын, агротехник техникумны күрсәттеләр. Җитәкче район советы утырышында да катнашты. Балык Бистәсенә тәнкыйть тә эләкте, мактауга лаек эшләре дә булды.

Утырышка кадәр Рөстәм Миңнеханов «Русский Мрамор» агросәнәгать комплексын карады. Компания «X5 Retail», «Магнит», «Лента», «ОКЕЙ» кебек федераль ритейлер һәм сәүдә челтәрләре белән хезмәттәшлек итә. Ит эшкәртү комплексы бөтен җитештерү циклларын – азык сыйфатыннан башлап, итне ваклап сату нокталарына илтеп сатуга кадәр контрольдә тота. Рәис «Русский мрамор»ның җитештерү күләме, әзер продукцияне сату географиясе белән кызыксынды.

Балык Бистәсендәге агротехник техникумда авыл хуҗалыгы өчен кирәкле белгечләр әзерлиләр. Рөстәм Миңнеханов тармак өчен эшче куллар әзерләү белән активрак шөгыльләнергә киңәш итте. Аның сүзләренчә, бүген мондый белгечләргә хезмәт базарында ихтыяҗ зур.

Совет утырышында исә Рөстәм Миңнеханов районның «йомшак» урыннарын телгә алды. Рәис әйтүенчә, Балык Бистәсенең потенциалы зур, әмма ул әле республика муниципалитетлары арасында 39 нчы урынны гына били.

– Күрше районнар белән чагыштырганда, күрсәткечләрегез бик яхшы. Әмма үсәргә дә үсәргә кирәк әле. Эш урыннары булдырырга кирәк. Район логистика ягыннан уңайлы җирдә урнашкан, су һәм җир ресурслары бар. Район потенциалын ачарга кирәк, – диде республика Рәисе.

Терлекчелек тармагына да тәнкыйть сүзләре әйтелде. «Күрсәткечләрегез – оят һәм хурлык. Терлекчелек – керем агымын тәэмин итә алырдай нигез ул», – диде Рөстәм Миңнеханов. Райондагы терлек тоткан фермаларны үрнәк итеп китереп, андый башлангычларны хупларга һәм үстерергә кирәк, дип киңәш итте ул.

СЕЗ ҺӘРВАКЫТ КИРӘК

Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин А.П. Обыденнов исемендәге Казан автотранспорт техникумы студентларына шулай диде.

Техникум эшчәнлеге белән танышканда Фәрит Мөхәммәтшин уку сыйныфлары һәм остаханәләренең югары дәрәҗәдә һәм заманча җиһазландырылган булуына игътибар итте. «Һөнәрне үзләштерү өчен менә дигән шартлар тудырылган», – дип билгеләп үтте ул.

Уку йорты директоры Айрат Имамиев сүзләренә караганда, техникумда җиде остаханә бар. Андагы җиһазларның күпчелеге дөнья стандартларына туры килә.

– Бу техникумга килү, сезнең белән очрашу минем күптәнге хыялым иде. Югары белемем буенча инженер-нефтьче булсам да, мин үземне автомобилист дип саныйм, – диде ул студентлар белән очрашуда. – Икътисадның бер генә тармагы да транспорт хезмәте һәм логистикадан башка яши алмый. Сезнең һөнәр һәрвакыт кирәк. Сезгә республика предприятиеләрендә генә түгел, Татарстаннан читтә дә ихтыяҗ булачак.

Фәрит Мөхәммәтшин студентларга һөнәри әзерлекнең мөһимлеге турында сөйләде.

– Төзелеш техникумының автотранспорт факультетын тәмамлагач, мин автотранспорт конторасында шофер булып эшли башладым. Күп нәрсәне өйрәнергә туры килде. Ул белемнәр тормышта бик кирәк булды, – диде ул. – Биредә теоретик белем, практик күнекмәләр алып, сез сайлап алынган тармакта конкурентлыкка сәләтле белгечләр булачаксыз. Сезгә тик тырышып укырга, белем алырга, җәмгыять өчен актив һәм кирәкле булырга омтылырга кирәк.

Фәрит Мөхәммәтшин Казан автотранспорт техникумы аның исемен йөрткән Александр Обыденнов турындагы истәлекләре белән дә уртаклашты.

– Александр Павлович республика автомобиль транспорты үсешенә зур өлеш кертте. Бик талантлы оештыручы, транспорт өлкәсендә көчле белгеч иде. Обыденнов исемен алган өчен техникум коллективына зур рәхмәт! Аның эшләгән эшләрен, белемнәрен яңа буынга җиткерү бик кирәк, – диде ул.

Ләйсән САФИНА

Яшь көч

Балаларын фән өлкәсенә җәлеп итәргә теләүче әти-әниләр соңгы елларда 20 процентка арткан. Яшь галимнәр дә елдан-ел күбәя бара. Бу саннарны Татарстан Фәннәр академиясе вице-президенты Вадим Хоменко яшь галимнәр, студентларга дәүләт стипендияләре тапшыру тантанасында җиткерде. «Республиканың иң яхшы яшь галиме» бәйгесендә 21 галим җиңүче дип табылган.

– Фән үсеше, белгечләр әзерләү мәсьәләләре республика өчен зур әһәмияткә ия. Татарстан ил төбәкләрен фәнни-технологик яктан үстерү буенча илкүләм рейтингта – бишенче урында. Бу – республикада хезмәт куючы 13 меңләп галимне берләштергән бергәлекнең казанышы. Шул исәптән, яшь галимнәрнең дә. Бүген аларга белемнәрен, сәләтләрен куллану өчен мөмкинлекләр җитәрлек. Төрле грант, стипендия программалары, фәнни премияләр бар. Татарстанда фәнни эшчәнлек өчен еллык чыгымнар 20 миллиард сумнан артып китте, – диде Фәрит Мөхәммәтшин Милли китапханәдә узган очрашуда.

Фәрит Мөхәммәтшин яшь галимнәрне Россия фәне көне белән котлап, аларны республиканың киңкырлы икътисадын үстерү өчен үз өлешләрен кертергә чакырды. Яшь белгечләрнең фәнни ачышлары турында сөйләгәндә, күптән түгел фән һәм инновацияләр өлкәсендә «Россия Федерациясе Президенты премиясе лауреаты» дигән мактаулы исемгә лаек булган КФУ доценты Ирек Мөхәммәтдиновны үрнәк итеп китерде. Хәзерге буын галимнәренең, остазларының эшен дәвам иттереп, Татарстанның данын еракларга танытуын әйтте.

Татарстанның яшьләр эшләре буенча министры Ринат Садыйков белдергәнчә, бүген фәнгә дәүләт, җәмәгатьчелек, ә иң мөһиме эре сәнәгать предприятиеләре, коммерцияле оешмалары тарафыннан зур игътибар бирелә. Яшь галимнәр һәм белгечләрнең республика иҗтимагый хәрәкәте җитәкчесе Юлия Кареева да яшь галимнәр өчен мөмкинлекләрнең күп булуына басым ясады:

– Конкурска барлыгы 150 гариза кабул ителде, бу сан елдан-ел арта. IT, медицина, төзелеш, архитектура… Һәр юнәлеш популяр. Хезмәтләр арасында новаторлык эшләнмәләре, кызыклы тикшеренүләр дә бар.

Әнә Казан дәүләт медицина университеты аспиранты Юлия Абдуллина «Табигый фәннәр өлкәсендә иң яхшы аспирант» номинациясендә җиңгән. Юлия белдергәнчә, хәзерге вакытта педиатриядә балаларга инъекцияләр эремәләренең махсус дозировкалары юк. Шуңа күрә табиблар дару препаратларын олылар дозасында кулланырга мәҗбүр. Ампуланың тулы күләмен куллану финанс югалтуларына китерә дип саный ул. Шуңа күрә балалар инъекцияләре эремәләре дозировкаларын оптимальләштерү буенча методик тәкъдимнәр эшләү белән шөгыльләнә һәм балалар дозасына патент алырга хыяллана.

Татарстан Фәннәр академиясе вице-президенты Вадим Хоменко фәндә төп авырлыкның яшьләргә төшүен, нәкъ менә шушы чорда төп ачышлар ясалуын әйтте.

– Минем фәнни хезмәткәрем: «Бер кимчелегең бар: син бик яшь», – дигән иде. Әмма бу кимчелек бик тиз үтә. Шуңа күрә яшь вакытта бик нык тырышырга кирәк. Вазгыять авыр дип тормыйлар, бүген фәнгә яшьләр күп килә. Программалар галимнәрне үзебездә калдыру өчен эшләнә, – диде Вадим Хоменко.

Сәрия МИФТАХОВА

МАЛНЫ ЯРАТУ ГЫНА ҖИТМИ

Авыл хуҗалыгы

Авылларда, эре хуҗалыкларда эшләргә мал табиблары җитми. Республикада алар белән тәэмин ителеш 80 процентны тәшкил итә. Сәбәп нидә? Яшь белгечләрне әлеге һөнәргә ничек җәлеп итәргә мөмкин?

Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе җитәкчесе Алмаз Хисаметдинов әйтүенчә, ветеринария берләшмәләре карамагындагы ветеринарлар белән тәэмин ителеш 100 процентны тәшкил итә. Ә менә халык белән көн саен элемтәдә була торган белгечләргә кытлык зур. Чистай (тәэмин ителеш – 65%), Алабуга (64%), Лаеш (56%), Югары Ослан (50%) һәм Балык Бистәсе (50%) районнарында вазгыять аеруча катлаулы.

Балык Бистәсе районының ветеринария берләшмәсе җитәкчесе Динар Сөләйманов әйтүенчә, районга кайткан яшь белгечләрнең бик азлары гына төпләнеп кала.

– Иң зур авырлык – көндәлек эшләрне башкаручы белгечләр җитмәү. Хезмәт хаклары белән кызыктырырга кирәк аларны. Күпчелеге бер ел да эшләмичә китә. Йортлар да салырга кирәк, тик моның өчен алар бераз эшләргә тиеш, дип саныйм. Элек мал табиблары, укуны тәмамлагач, авылларга кайтып, кимендә өч ел эшли иде. Шуны кабаттан кайтарырга кирәк. Хәзерге вакытта бездә эшләүчеләрнең күпчелеге – урта буын. Алар барысы да диярлек – кайчандыр укуны тәмамлап, безгә эшкә кайтучылар, – диде ул.

Әлмәт районында яшәүче Айдар Габдрахманов җиденче ел участок мал табибы булып эшли. Ул 14 авыл өчен җаваплы.

– Безнең эштә иң мөһиме – авылны һәм малларны ярату. Ә андыйлар, кызганыч, бик күп түгел, – ди ул. – Чыннан да, мал табибларына кытлык барын үзебез дә сизәбез. Чөнки яшьләр зур терлек белән эшләргә бик кызыкмый. Миңа калса, яшь белгечләрне авылларга, хуҗалыкларга эшкә кайтарыр өчен шартлар булдырырга, әйтик, йортлар салырга кирәк. Минем үземнең дә әлегә йортым юк. Бу мәсьәлә кайчан да булса уңай хәл ителер дип өметләнәм. Чөнки мин үз эшемне бик яратам, аны алыштырырга теләмәс идем. Авыл укытучыларына, табибларга төрле программалар булган кебек, мал табибларына да булдырылсын иде алар.

Айдар фикеренчә, студентларга укыган вакытта ук хуҗалыкларга кайтып практика узу бик мөһим.

– Мин Минзәлә авыл хуҗалыгы техникумын тәмамладым. Ул вакытта практиканы Аю авылында узган идек. Бик күңелле, рәхәт чаклар булды ул. Аннан соң Бишмунча авылына «Чулпан» хуҗалыгына кайттым. Эшкә тотынгач та авырлык булмады, чөнки мал арасында үскән авыл малае буларак, бар күңелемне биреп эшләдем. Күрше-тирә авылларда мал табиблары булмагач, миңа еш мөрәҗәгать итәләр. Авырсынмыйча, чакырган җиргә сөенеп барам, – диде ул.

Алмаз Хисаметдинов сүзләренчә, мал табиблары җитмәүнең берничә сәбәбе бар. Беренчесе – хуҗалык җитәкчеләренең яшь белгечләргә тиешле шартлар тудырмавы.

– Бу хезмәт хаклары, торак һәм транспортка кагыла, – ди ул. – Шуңа күрә хуҗалыкта эшләп калучы егетләр аз. Белгечләр күпмедер вакыттан соң яңа эш эзли башлый. Беркемнең дә 20 мең сумга гына эшлисе килми, билгеле. Бу турыда онытырга ярамый.

Икенче сәбәбе – хуҗалыкларда яшь белгечләрне калдыру буенча дәүләт сәясәте булмау.

– Белгечләрне укытуга киткән бюджет акчасы тиешле нәтиҗә бирми, чөнки алар үз белгечлеге буенча эшләми. Киләчәктә без Дәүләт Советына мөрәҗәгать итеп, әлеге мәсьәлә буенча Дәүләт Думасына закон инициативасы белән чыгарга планлаштырабыз. Безнең уебызча, бюджет акчасына укыган студентлар кимендә өч ел булса да үз белгечлеге буенча эшләргә тиеш, – диде Алмаз Хисаметдинов.

Казан дәүләт ветеринария медицина академиясе ректоры Рөстәм Равилов фикеренчә, гадәти белем бирү белән бергә кабаттан практик тәҗрибәгә күчәргә кирәк. Хәзерге вакытта күпчелек уку йортларының студентлары төрле сәбәпләр аркасында практика узу мөмкинлегеннән мәхрүм ителгән.

– Нәтиҗәдә вуз студентлары үз профессияләре турында китаптан гына укып белә, ә гамәли белем җитми, – ди ул. – Алар яңа технологияләрне тиз арада үзләштерә алмый, эш бирүчеләргә дә аларны кабаттан эшкә өйрәтер өчен вакыт һәм энергия сарыф итәргә туры килә. Укытучыларга да практик гамәлләргә өйрәнергә кирәк булачак.

Моннан тыш, чыгарылыш сыйныф укучыларын әлеге һөнәргә җәлеп итү буенча да эшләр башкарырга кирәк, дип саный ул.

– Чыгарылыш студентлары авылга эшкә барсын өчен, мәктәп укучылары белән эшләүне иртәрәк, 7–8 нче сыйныфлардан ук башларга кирәк. Абитуриентларны максатчан укуга да җәлеп итәргә, кызыксындырырга кирәк. Чөнки вузны тәмамлагач, максатчан укыган студентларның 99,5 проценты эшкә урнаша. Тик, кызганыч, районнарда кызыксыну юк. Узган ел ахырында районнарга максатчан килешү нигезендә укырга теләге булган мәктәп укучыларын безгә җибәрүне сорап, хатлар юллаган идек. Алай гына да түгел, бу мәсьәләдә без һәрдаим районнарның авыл хуҗалыгы идарәләре белән элемтәдә торабыз. Хәзерге вакытта 43 районның бары тик өчесе генә кандидатлар җибәрде. 9 район, кирәкми, диде, 31е хәтта җавап та бирмәде.

Зөһрә САДЫЙКОВА

Милләттәшләр

ШАХТЕР ЕГЕТ КҮМЕР КИСӘ

Бөтендөнья татар конгрессының Татар төбәкчеләре белән эшләү комитеты җитәкчесе Альберт Борһанов Пермь, Кузбасс шахталарында эшләгән шахтерларны, бу эшкә нисбәтле галимнәрне очраштырды.

Сәбәбе дә бар. Пермь шахталарында гади эшчедән башлап, академик дәрәҗәсенә күтәрелгән милләттәшебез, Россиянең атказанган шахтеры, атказанган энергетигы һәм башка тагын бик күп исемнәргә, хөкүмәт бүләкләренә лаек булган Апас егете **Данир ЗАКИРОВ** шахтерлар турында ике китап язган. Аның беренчесе тарихи вакыйгаларны үз эченә алып, фәнни юнәлештә булса, икенчесе гомерләренең күп өлешен шахталарда үткәргән, шул рәвешле илебез үсешенә зур өлеш керткән милләттәшләребезгә багышланган. Автор белән шахтер татар егетләренең язмышы турында сөйләштек.

:: Данир Галимҗанович, кайсы гына авыл тарихына кагылсаң да, шахталарга киткән гаярь егетләр турында сүз булмый калмый. Хәтта ялга кайткан вакытларда да алар туган җирләрендә яңа тормыш өчен көрәш алып барганнар, авылдашларына ярдәм иткәннәр. Аларга ышанганнар. Шундый сорау туа: шахтер егетләребез ничек шулай көчле рухлы булып кала алганнар?

– Шахтерлар яшәгән төбәкләрдә татарлар диаспора булып кына яшәмәгән, алар җирле халыкка әйләнгәннәр, чын хуҗа булып яшәгәннәр. Инде XIX гасыр ахырында ук шахталарда татарларның саны кискен арта. Ә XX гасырдагы «халыкларның бөек күчеше» нәтиҗәсендә исә Урал һәм Себернең сәнәгать алга киткән шәһәрләрендә мөселман җәмгыятьләре барлыкка килә. Сталинның беренче бишьеллыклары чорында гына да, ягъни 1930 нчы елларда, «коммунизм төзелешләре»нә, Татарстаннан 300 мең кеше китә. Бу бит республиканың һәр унынчы кешесе дигән сүз. Мәсәлән, Бөек Ватан сугышы башланганда, Донецкидагы күмер шахталарында Татарстаннан килгән эшчеләрнең саны 100 меңнән артып китә. Шунысы игътибарга лаек: татар башка милләтләр арасында эреп югалмый. Телне, мәдәниятне, гореф-гадәтләрне саклап, бер йодрык булып яши. Әнә шулай берләшеп яшәү, проблемаларны, авырлыкларны бергәләп җиңү шахтерларның рухын баеткан, көчле иткән.

:: Сез бу китапта тарихны XIX гасырдан гына түгел, шактый ерактан башлагансыз...

– Урал металлургиясе тарихына – 300 ел. Шул вакыттан бирле күпме чыганаклар ачылган, заводлар төзелгән, руда табылган. Бу эшләрнең берсе дә татарсыз эшләнмәгән, милләттәшләребез бик актив булган. Арада исемнәре шактый мәгълүм кешеләр дә бар. Мәсәлән, алтын табучы, меценат, шагыйрь Закир Рәмиевне белмәгән татар юктыр дип уйлыйм. 1869 елда аның әтисе Мөхәммәтсадыйк зур булмаган алтын приискы сатып ала. Соңрак бу гаиләнең 20гә якын шахтасы була. Алар татар халкы өчен мәдрәсәләр, мәктәпләр ачалар, укытучылар белән тәэмин итәләр.

Тагын да тирәнгәрәк төшсәк, хәзерге Пермь краеның Куян авылында туып-үскән Тасим Мәмәтов – зур эшләр башкарган күренекле милләттәшләребезнең берсе. 1739 елда һәр кешегә тау эше белән шөгыльләнергә мөмкинлек бирүче хөкүмәт указы чыга. Тасим Мәмәтов, шуннан файдаланып, бакыр рудалары чыганакларын ача. Бу эшкә авылдашларын, туганнарын җәлеп итә. Ул төзегән Егошихин заводлары Пермь шәһәре салынуга нигез булып тора. Гомумән, Пермьнең генә түгел, Губаха, Гремячинск һәм башка шахтерлар яши торган шәһәр-бистәләрнең барлыкка килүендә, үсеш алуында һәр чорда диярлек татарларның роле бик зур була. 1773 елда Тасим Мәмәтовның улы Исмәгыйль акчасына Санкт-Петербургта Тау училищесы ачыла, соңрак ул институтка әверелә. Исмәгыйль Тасимов туган җирендә дә тау эшләре буенча белгечләр әзерләүче белем йорты ачу турында хыялллана. Әмма бу озаккарак сузыла, аның хыялы бары тик 180 елдан соң гына, ягъни 1953 елда тормышка аша. Мин үзем дә шушы уку йортында белем алдым.

:: Пермь якларына нинди җилләр ташлады?

– 18 яшьтә Кизел шәһәрендәге күмер бассейнына акча эшләргә дип килеп чыктым. Аңа кадәр Яшел Үзәндә һөнәр училищесын тәмамлаган идем. Ике ел авылдан ерак түгел машина-трактор станциясендә токарь булып эшләдем. Йортыбыз бик тузган иде. Шуны ремонтлыйм дип, бурычка баттым. Ничек тә түләү җаен табарга кирәк булды. Ул вакытта Кизелда кышларын акча эшләп йөрүче авылдашлар шактый иде. Сәламәтлекләрен туздырып, әмма кесә тулы акча белән кайтып төшәләр. Кайберләре хәтта күкрәкләренә орден да тагып кайтты. Беркайчан да зарланганнарын ишетмәдем. Ерак бер туганым Кизелда яши иде. Тәвәккәлләп, туры аларга киттем. Дөресен әйтим, килеп төшкәч тә, бу җирләр миңа бөтенләй ошамады. Корым белән капланган кап-кара шәһәр, хәтта карның ак төсе дә күренми иде.

Зур хезмәт хакы бирәләр дигәч, тау казучы булып урнаштым. Акчасына күрә, хезмәте дә бик авыр иде. Әмма мине мондагы эшчеләрнең хезмәткә уңай карашы, дус-тату булулары нык гаҗәпләндерде. Шахтада нык бәдәнле кешеләрнең генә эшли алганын беренче көнне үк аңладым. Тырышырга кирәк иде. Нәтиҗәләр озак көттермәде. Социалистик ярышларда җиңү яулый башладым, спорт белән шөгыльләндем, институтка укырга кердем. Һәм шулай килеп чыкты: мин шахталарны ташлап китә алмадым...

Данир Закиров институтны тәмамлагач та, Кизел шахталарында эшен дәвам итә. Тау мастерыннан башлап, директор дәрәҗәсенә күтәрелә. 13 ел җир астында эшли. Читтән торып Пермь политехник институтының аспирантурасын тәмамлый. Шул вакыттан фән дөньясына чума. Бөтенсоюз әйләнә-тирәлекне саклау институтында директор урынбасары итеп тәгаенләнә. Көнбатыш Урал энергетиклары ассоциациясендә генераль директор булып эшли. 50гә якын яңалык уйлап таба һәм аларга патент ала. 2009 елдан – Россия фәннәр академиясе Тау институтында Урал бүлегенең баш фәнни хезмәткәре, техник фәннәр докторы, профессор. Бик күп хөкүмәт бүләкләренә ия. Пермь шәһәрендә Татар милли-мәдәни автономиясен җитәкли.

:: Сез – бик тә уникаль шәхес. Техник юнәлешне алып бару белән бергә, гуманитар өлкәне дә үз итеп, китаплар язарга да вакыт табасыз. Бу эшне дәвам итәргә уйлыйсызмы?

– Безнең якташларыбыз Донбасс шахталарында бигрәк тә күп булган. Хәтерләсәгез, җырларда да шул яклар күбрәк телгә алына бит. Дөньялар тынычланган, архивларда актарынып, шахтерлар белән очрашып, аларның тарихын язасым килә. Донбасс шахтерлары бүген күмер чабып кына калмыйлар, ирек өчен көрәш тә алып баралар. Димәк, алар хакында тарих битләренә язып калдыру бигрәк тә кирәк.

Әңгәмәдәш – Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

МУЗЕЙ КИРӘК

Искә алу

Февраль ае электән мәктәпләрдә хәрби-патриотик тәрбия бирү айлыгы буларак билгеләп үтелә. Безнең өчен бу ай бигрәк тә якын. Чөнки бөтен гомерен сугыш батырларын барлауга багышлаган якташыбыз Шаһинур абый Мостафинның да туган көне шушы айда.

Шаһинур Әхмәтсафа улы Мостафин 1948 елның 12 февралендә Татарстанның Мамадыш районы Арташ авылында Бөек Ватан сугышында Александр Матросов батырлыгын кабатлаган әтисе Әхмәтсафаның унбер балалы гаиләсендә өлкән малай булып туа.

Шаһинур Мостафин – үзенчәлекле шагыйрь, ялкынлы публицист, документаль проза өлкәсендә эшләүче каләм остасы. Тынгысыз җанлы эзтабар әдип буларак, әтисе васыятен үтәп, яу кырында мәңгелеккә ятып калган каһарманнарыбызны барлау, аларның кылган батырлыкларын, якты исемнәрен хәзерге һәм киләчәк буыннар хәтеренә җиткерү юнәлешендә армый-талмый эшләде. Аның җитәкчелегендәге «Хәтер яктысы» экспедициясе әгъзалары соңгы елларда гына да, хәрби архивларда кат-кат эшләп, Балтыйк буе һәм Кавказ республикаларында, Волгоград, Донецк, Кировоград, Орёл, Ленинград, Львов, Мәскәү, Псков өлкәләрендә, Карелиядә һәм Алманиядә булып, Бөек Ватан сугышының моңарчы билгесез булган батырлары турында бай мәгълүматлар туплап кайттылар. 2000 елда, Бөек Җиңүнең 55 еллыгы уңаеннан, татар һәм рус телләрендә дөнья күргән «Батырлар китабы» – «Книга Героев»ның баш консультанты, кереш сүз авторы һәм мөхәррире дә булды Шаһинур Мостафин. Җиңүебезнең 60 еллыгын исә ул «Хәтер яктысы» дигән документаль-публицистик язмалар китабы белән каршылады. Әлеге энциклопедик басмада Бөек Ватан сугышының моңарчы «хәбәрсез югалды» дип саналган яисә аз билгеле булган каһарманнары турында тәфсилләп сөйләнелә. Әлеге китабында Шаһинур Мостафин татарларның Бөек Ватан сугышындагы ролен раслаучы төрле документлар, зур хәрби җитәкчеләрнең сүзләрен дә китерә. Мәсәлән, Советлар Союзы Маршалы И.С. Конев: «Татарстанда туган егетләр... арысланнар кебек сугыша», – дигән.

Бөек Җиңүнең 70 еллык юбилеен да лаеклы каршылады ул. «Онытырга мөмкин түгел», «Алар – Җәлил йолдызлыгыннан!», «Үлмәс моң варислары» исемле китапларын чыгарды.

Соңгы елларда – Бөек Ватан сугышы тарихына да, аның җиңүчеләренә дә мөнәсәбәт төрлеләнгән, катлаулыга әйләнгән аңлаешсыз чорда – бу четерекле теманы Мостафин кадәр җигелеп тартучы бүтән милләттәшебез юк безнең. Язучы, каһарманнарыбызны эзләп табу, гаярь шәһитләрне дөньяга белгертү белән генә чикләнеп калмыйча, аларга туган якларында һәйкәлләр дә куйдырды. Андый һәйкәлләрнең саны 28гә җиткән! Шуларның берсе – Мамадыш шәһәре уртасындагы Урта Кирмән авылының 8 улын да сугышка озатып, әмма берсен дә исән килеш кабат күрә алмаган Фәтиха Әхмәдиева һәйкәле.

Саулыгы һәм байлыгы хакына, бөтен гомерен шушы изге эшкә багышлаган якташыбызның хезмәтләре дәүләт тарафыннан да, ил күләмендә дә югары бәяләнде.

2017 елдан әлеге олпат затыбыз каты авыру белән көрәште, уннан артык операция кичерде. Шул килеш тә ул кулыннан каләмен төшермәде, Бөек Җиңүнең 75 еллыгын каршылап, татар һәм рус телләрендә ике китап әзерләп чыгарды.

Ләкин мәкерле чир Шаһинур аганы 2020 елның 6 июнендә арабыздан алып китте. Аның үзеннән соң бик бай әдәби мирасы калды. Аларның таркалып, юкка чыгуына юл куймаска иде. Шаһинур Мостафинның туган һәм үскән йортында, Мамадыш районының Арташ авылындагы туган нигезендә аның әдәби-мемориаль музее булдырылса, аның рухы каршында йөзебез ак булыр иде. Татарстанда Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елы кысасында, язучының 75 еллык юбилей елында бу башлангыч яклау табып, югары даирәләрдә дә ишетелеп, хуплануына өметләнәм.

Ринат ХӘЙРУЛЛИН,
Мамадыш районы
Урта Кирмән урта мәктәбенең
тарих укытучысы

Ит урынына – чикерткә?

Татарстан дәүләт идарәсен цифрлы үстерү, мәгълүмати технологияләр һәм элемтә министры Айрат Хәйруллин республикада микротерлекчелекне үстерү турында уйланырга тәкъдим итте. Белгечләр исә, ата-бабалар чикерткәсез яшәгән, ансыз да яшәрбез, ди. Ә сез бөҗәкләр ашарга әзерме?

Җаны теләгән елан ите ашаган

Гыйнвар аенда Европада өй чикерткәләрен ашарга рөхсәт итүне күздә тоткан яңа закон гамәлгә керде. Айрат Хәйруллинның да үзенең телеграм-каналында ризык итеп куллану өчен чикерткә үрчетергә тәкъдим итүе күпләрне гаҗәпкә калдырды. Бөҗәк ашау безнең өчен бигрәк чирканчык нәрсә булып тоела бит ул. «Иткә бик яхшы алмаш. Итне җитештерүгә караганда экологиягә дә азрак зыян сала», – дигән фикердә Айрат Хәйруллин. Әлеге бөҗәкләрдә аксым, витаминнар, клетчатка, минераллар күп икән.

Министр Европа берлегенең чикерткә порошогын төрле ризыкларда куллануны хуплавын да телгә алган. Шул ук вакытта: «Спортчылар өчен бөҗәк онынннан ясалган батончиклар бар инде. Аларны күбрәк кешенең куллануына ничегрәк карыйсыз?» – дип, башкаларга да уйланырга урын калдырган ул.

Газетабызның «ВКонтакте» сәхифәсендә дә әлеге хәбәргә карата укучыларыбыз төрле фикерләр язган. Әлбәттә, алар бака да, таракан да, чикерткә дә ашарга риза түгел.

– Кайчандыр басуларда мал азыгы өчен балтырган үстереп караганнар иде. Нәтиҗәдә табигатьнең иң гүзәл урыннары юкка чыкты. Бездә яхшы булсын дип башлыйлар, әмма начар тәмамлана. Әйдәгез, моңарчы ашаган ризыкны гына ашап яшик әле. Инде безнең геннар шуңа ияләнгән. Басу-кырларыбыз да чиксез, – дигән Зөлфия Гыймадиева.

Татарстан Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының матбугат үзәгеннән, өй чикерткәсе үрчетүче яки бу эш белән шөгыльләнергә теләүче фермерлар юкмы, дип кызыксындык. «Бездә андый хуҗалыклар юк», – дип җавап бирделәр.

Эшкуарларның үзләренең дә фикерләрен белештек. Баулы районында авылда лаборатория ачып, анда бодай үрентесеннән продукция ясап сатучы, заманча фикерле Әхмәтовлар бар.

– Мондый мәгълүматны ике ел элек ишеткән идек инде. Ул вакытта ирем: «Бу җирәнгечне ашаучылар булырмы икән?» – дип гаҗәпләнгән иде. Безнең җитәкчеләрнең чикерткә ашарга тәкъдим итүенә аптырадык. Аны ашау яхшы түгел. Без чикерткә үрчетү белән шөгыльләнә алмас идек, – диде Алинә Әхмәтова.

Корт түгел, ит!

Балык Бистәсе районы башкарма комитетының инвестицияләр җәлеп итү бүлеге җитәкчесе Дилүс Гатиятовның да фикерен белештек.

– Микротерлекчелек белән шөгыльләнергә кушу – башка сыймаслык нәрсә. Савым сыерларын, ит токымлы мөгезле эре терлекләрне арттырырга кирәк. Чикерткә үрчетү хет шунда миллиард сумлык табыш китерсен, эш түгел бу. Авыл хуҗалыгын күтәрү турында уйларга кирәк. Республикада менә дигән кошчылык фабрикалары бар. Үз җирлегебездә тырышып эшләсәк, халкыбызны туйдырырлык көчебез дә, җиребез дә, мөмкинлекләребез дә бар, – диде Дилүс Гатиятов.

Балтач районының күппрофильле Салавыч лицееның биология укытучысы Резеда Бадгиева исә, кеше киләчәктә бөҗәкләр куллана башлар, дигән фикердә.

– Бу минем өчен яңалык түгел. Кайбер илләрдә бөҗәкләрнең җитлеккән затлары (имаго) яки аларның кортлары белән тукланганнарын ишеткәнем дә, укыганым да бар. Кайбер бөҗәкләр кеше организмына файда китерүче аксым, витаминнарга бай. Аларны кайбер җитди авыруларны дәвалау өчен кулланалар. Кеше бөҗәкләр ашый башлармы, дигән сорауга килгәндә, башлар дип уйлыйм. Галимнәр, тикшеренүләр уздырып, аларның файдалы якларын күбрәк ачсалар, адәм баласы да бөҗәк ашауга күчәргә мөмкин. Шуны да онытмаска кирәк: алар төрле авыруларны таратучылар да булып торалар, – ди Резеда Бадгиева.

Фикер

Илһам хәзрәт САБАНЧИН,
Татарстан Диния нәзарәтенең Шәригать мәсьәләләре буенча бүлек белгече:

– Хәнәфи мәзһәбе буенча, бөҗәкләр ашау тыелган («Әл-Мәбсут», имам әл-Сәрахси, 11/399 һ.б.). Галимнәр фикеренчә, моның сәбәбе – бөҗәкләрнең җирәнгеч кыяфәте. Бу хакта «әл-Әгъраф» сүрәсенең 157 нче аятендә әйтелә: «Ул аларны яхшылыкка өнди, начарлыклардан тыя, пакь нәрсәләрне аларга хәләл итә, кабахәт нәрсәләрне исә аларга хәрам кыла». Моннан искәрмә булып саранча тора, Мөхәммәд пәйгамбәр аны ашарга рөхсәт иткән («Әс-Сунан әс-сәгыйр», имам әл-Бәйхакый).

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитеты рәисе урынбасары Таһир Һадиев сыерлар киләчәктә дә кирәк булачак дип саный. «Без бит әле болай гына түгел, авыл сөте, авыл тавыгы дип ашыйбыз», – ди ул.

– Әгәр дә йорт хайваннары дисәк, тавык, куян, күркә ите ашыйбыз. Атны, сарыкларны суябыз. Чит илләр бөҗәк ашау мәсьәләсен күптән күтәрә. Ясалма ит тә җитештереп карадылар. Һәр нәрсәне ясап, үлчәп карыйлар. Дөрес, барысы да уңай гына килеп чыкмый, – ди Таһир Һадиев.

Таһир Һадиев белдергәнчә, адәм баласын җир туендыра. Бигрәк тә безнең якларда. Тик сөрүлек җирләр елдан-ел кими. Бу җирләргә юллар салалар, сатып та алалар... 1961 елда республикада яшәүче бер кешегә 120 сутый җир туры килсә, хәзер ул 80 сутыйдан артмый. Шуның өчен министрның сүзендә уңай фикер ята дип саный ул.

– Бу – ниндидер юлларның берсе. Миңа калса, ияләшмәгән кешегә, бәлкем, кирәк тә булмас. Кешегә ашатканчы, башта малларга ашатып карарга кирәк. Аларның рационына һәрвакыт ниндидер кушылмалар өстәлә. Үзебез дә кара ипи ашап, су гына эчмибез, төрле витаминнар кулланабыз, – диде Таһир Һадиев.

Кем белсен, киләчәктә, бәлки, адәм баласына чикерткәдән җитештерелгән ризыклар да ашарга туры килер. Монысын вакыт күрсәтер. Әлегә исә борынны җыерабыз. Бөҗәкләр – бөҗәк, ә без кеше булып калыйк.

Сәрия МИФТАХОВА

КОТЛЫЙБЫЗ!

Югары квалификацияле белгечләр әзерләүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле фәнни-педагогик эшчәнлеге өчен «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесе Идарә, икътисад һәм финанслар институтының исәпкә алу, анализ һәм аудит кафедрасы профессоры-консультанты **Ивашкевич** Виталий Борисович, музыка сәнгатен үстерүгә мөһим өлеш кертүе, күпьеллык нәтиҗәле иҗади эшчәнлеге өчен «Муса Җәлил исемендәге Татар академия дәүләт опера һәм балет театры» дәүләт бюджет учреждениесе вокалчы артисты (солисты) **Казаков** Михаил Владимирович, татар мәдәниятен саклауга һәм музыка сәнгатен үстерүгә мөһим өлеш кертүе, күпьеллык иҗади эшчәнлеге өчен «Акчарлак» нәшрият йорты» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең вокалчы солисты **Сафин** Габделфәт Габдерахман улы, республиканың ветеринария ягыннан иминлеген тәэмин итүгә мөһим өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «Кызыл Шәрык Агро» акционер җәмгыятенең Әҗил терлекчелек комплексы ветеринария табибы **Таһиров** Илфат Рәшит улы **«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены медале** белән бүләкләнде.

* * *

Казан шәһәре Вахитов районының «СОлНЦе» махсуслаштырылган олимпиада-фәнни үзәге» урта гомуми белем бирү мәктәп-интернаты» аеруча сәләтле укучылар өчен муниципаль автоном гомуми белем бирү учреждениесенең физика укытучысы **Әфләтунов** Наил Әбүзәр улына, Казан шәһәре Киров районының «Татар телендә белем бирелә торган 4 номерлы гимназия» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе директоры **Вахитова** Илхания Абзалетдин кызына, Казан шәһәре Авиатөзелеш районының «Аерым фәннәр тирәнтен өйрәнелә торган 54 номерлы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең рус теле һәм әдәбияты укытучысы **Воронина** Ирина Васильевнага, Казан шәһәре Вахитов районының «Татар телендә белем бирелә торган 27 номерлы гимназия» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең математика укытучысы **Гыйльмиева** Гөлназ Габделҗәвит кызына, Казан шәһәре Совет районының «141 номерлы гимназия» муниципаль автоном гомуми белем бирү учреждениесе директоры **Гыймадетдинова** Ирина Львовнага, Казан шәһәре Яңа Савиново районының «177 номерлы лицей» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең рус теле һәм әдәбияты укытучысы **Дасова** Рамилә Зиннәтулла кызына, Казан шәһәре Совет районының «224 номерлы катнаш төрдәге балалар бакчасы» муниципаль автоном мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе мөдире **Дорофеева** Резеда Шакир кызына, Казан шәһәре Мәскәү районының «2 номерлы лицей-интернат» муниципаль автоном гомуми белем бирү учреждениесенең җәмгыять белеме укытучысы **Җиһаншин** Илсур Рөстәм улына, Казан шәһәре Совет районының «47 номерлы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең туган тел һәм әдәбият укытучысы **Зиннәтова** Зилә Вәли кызына, Казан шәһәре Вахитов районының «13 номерлы урта гомуми белем бирү рус-татар мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе директорының тәрбия эше буенча урынбасары, география укытучысы **Курилова** Людмила Александровнага, Казан шәһәре Совет районының «110 номерлы лицей» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең математика укытучысы **Максимова** Валентина Васильевнага, Казан шәһәре Мәскәү районының «Татар телендә белем һәм тәрбия бирелә торган 294 номерлы катнаш төрдәге балалар бакчасы» муниципаль автоном мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе укытучысы-логопеды **Михайлова** Валентина Михайловнага, Казан шәһәре Совет районының «Балалар академиясе» балалар иҗаты үзәге» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе директоры **Насыйбуллина** Галина Алексеевнага, Казан шәһәре Совет районының «8 номерлы гимназия – Мәгариф үзәге» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе директоры **Пичугина** Марина Вавиловнага, Казан шәһәре Совет районының «Аерым фәннәр тирәнтен өйрәнелә торган 22 номерлы урта гомуми белем бирү мәктәбе – Мәгариф үзәге» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең чит тел укытучысы **Родионова** Наталья Ивановнага, Казан шәһәре Совет районының «Аерым фәннәр тирәнтен өйрәнелә торган 171 номерлы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең рус теле һәм әдәбияты укытучысы **Таксеитова** Лилия Равил кызына, Казан шәһәре Авиатөзелеш районының «33 номерлы гимназия» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең инглиз теле укытучысы **Урустемханова** Алсу Самат кызына, Казан шәһәре Совет районының «175 номерлы гимназия» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең рус теле һәм әдәбияты укытучысы **Ухванова** Галина Валериевнага, Казан шәһәре Яңа Савиново районының «23 номерлы лицей» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе директоры **Шакирҗанова** Альбина Җәүдәт кызына, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының «Югары Тегермәнлек урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең башлангыч сыйныфлар укытучысы **Мөбарәкшина** Дилә Мәгъсүм кызына **«Татарстан Республикасының атказанган укытучысы»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

Законлылыкны ныгытудагы, гражданнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклаудагы казанышлары өчен Казан шәһәренең Киров район суды рәисе **Соколов** Олег Валерьевичка **«Татарстан Республикасының атказанган юристы»** дигән мактаулы исем бирелде.

Ватан хакына



Солдат хатыны

Ирләребезгә кулдан килгәнчә ярдәм итәргә кирәк. Саба районының Шәмәрдән бистәсендә яшәүче Гүзәл Рамазанова әнә шулай ди. Аның Дамиры хәрби операциядә. Ул анда илен саклаcа, Гүзәл монда, тылдагыларны берләштереп, бер учка җыеп тора.

– Ирем армиядән сержант булып кайткан иде. Чакыру башлангач та, китәсен яхшы белде. Ул моңа әзер иде. Ике балабызны да әтиләренең озакка китәсенә әзерләдек. Илдәге хәлләрне чамалагач, мин үземне кулда тотарга өйрәндем. Ирләребезгә безнең елаганны күрү җиңел түгел икәнен беләм бит, – ди Гүзәл. – Бик рәхәттә яшәгәнбез икән бит без. Тормыш барысына да өйрәтте хәзер. Әле ярый ирем бар дип утырмаганмын, машина йөртергә өйрәнгәнмен дим. Дамир «Казан ЭКСПО»да чакта атна саен янына барып йөрдем.

Дамирны икенче эшелон белән алып китәләр. Алар Шәмәрдәннән 30 егет була. Менә шул 30 кешенең гаиләсе берләшеп, социаль челтәрдә үз төркемнәрен булдырганнар. Берсе элемтәгә чыкмаса, икенчесе борчылмаска дип хәбәр сала, ди.

– Ул төркемдә балаларын көтүче әниләр, ирләрен көтүче хатын-кызлар бар. Уйлар, хисләр уртак безнең. Әмма башны имибез. Ирләргә без терәк булырга тиеш. Балалар да әтиләрнең кайтуын көтеп торалар. Олысы 2 нче сыйныфта укыгач, кая киткәнен, нишләгәнен аңлый. Кечесенә әле 4 кенә яшь. Анысы үзалдына сөйләп тә йөри. Никтер ул әтисен киләсе кышта кайта дип көтә, – ди Гүзәл. – Ирем белән шулкадәр горурланам. Беләсезме, Казанда чакта бер көнгә өйгә алып кайттым. Юлда бер кибеткә туктадык. Шунда олы яшьтәге бер бабай килеп: «Улым, бармыйча калып булмыймы соң?» – ди. Шунда Дамир: «Мин сезне, гаиләмне сакларга тиеш бит, абый! Илемне яклап барам», – диде. Шул чакта тәннәрем чемердәп чыкты. Мин чын ир-ат ышыгында яшәгәнмен икән бит!

Дамир иркә малай булып үсми. Гаиләдә кызлардан соң көтеп алынган малай булса да, әти-әнисе аны чын ир итеп тәрбияли. Гүзәлне бер баласы белән кияүгә ала. Үзен дә ярата, сабыен да үз итә. Менә шушы адымы да аның чын егет икәнен күрсәтә.

– Әнигә бик кыен инде. Аны да аңлыйм. Кадерләп үстергән баласы бит. Мин аңа гел, көчле бул, дип кенә торам. Безгә генә килгән борчу түгел бит, ил белән күтәрәбез. Без – бик көчле халык. Авыр чакта бердәм була беләбез. Ирем дә: «Без монда бер гаилә кебек булып беттек инде», – ди. Без дә шулай. Районыбыз белән солдатларны кайгыртабыз. Элек Шәмәрдәндә гуманитар ярдәм җыю юк иде. Иремә һәм аның дусларына дигән күчтәнәчләрне башка волонтерлар аша биреп җибәрә идек. Уйлаштык та үзебез җыярга булдык, – ди Гүзәл.

Шушы көннәрдә алар җыйган ярдәм егетләргә киткән дә инде. Кирәк-ярактан башка, егетләргә хатлар да язып салганнар. Мәктәп укучылары рәсем ясаган. Солдатлар үзләре дә яшерми, әнә шул сабый кулы белән ясалган сурәтләрне күргәч, алардан килгән ихлас хатларын укыгач, күңелләре дә тула, шатланалар да.

Шул хатлар арасында әтисен өзелеп көтүче кызчыкныкы да була. Мәктәпкә бармаса да, язарга өйрәнгән бу сабый: «Әтием, мин сине яратам», – дип, зур хәрефләр белән язып җибәргән. Әтисе исә нәниенең хатын күкрәк түрендә йөртә.

– Кайчакта каты бәгырьле булып та тоеламдыр. Әмма мин көчле булырга тырышып яшим. Һәр сөйләшүемдә ирем моны сизә. Мин аның белән, ул минем белән горурлана. Бергә булганда, без барысын да җиңәчәкбез. Дамир тәмле бәлешләрне сагынганын да әйткәләп куя. Ул болай да пешергәнемне мактап ашый иде. Алла боерса, мул табыннар янына җыелып утырасылар алда әле. Исән-имин генә була күрсеннәр. Егетләрне көтәбез, – ди ул. – Бу аерылышу безне сынады. Бер-беребезнең кадерен белдек.

Ярдәм итү өчен исәп-хисап реквизитлары:
Гүзәл Илдус кызы Рамазанова исемендәге Саклык (Сбер) банкы картасы номеры:
4817 7601 0007 6334.
Карта 89393313593 номерына беркетелгән.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

«ВТ» КАЙДА – ШУНДА ФАЙДА

РЕКЛАМА БҮЛЕГЕ
(843) 222-09-65,
222-09-70.
E-mail:
vtreklama@mail.ru

КУНАКЧЫЛ МИҢГӘР

Саба төбәгендәге Миңгәр иң әүвәле халкыбызны Сабан туйлары белән үзенә җәлеп итте. Туган төбәкне, аның кешеләрен данлау, таныту, гореф-гадәтләрне яңарту ниятеннән башланган бәйрәм-тамаша Татарстан, Россия киңлекләрендә яхшы мәгълүм. Мишә буендагы тугайлыкта 50–70 меңгә якын төрле милләт вәкиле тамаша кылды, уеннарда көч сынашты, бүләген алды, Сабан туйлары елдан-ел мәртәбәлерәк, колачлырак була барды һәм киләчәктә дә шулай булачак.

Әлбәттә инде, һәр эштә башлап йөрүче, үрнәк күрсәтүче кирәк. Моннан 20–25 ел элек туган төбәген данлы, шөһрәтле итүгә Җәүдәт Мидхәт улы Миңнәхмәтов җиң сызганып алынды. Уллары Ирек (урыны җәннәт түрендә булсын), Радик әтиләренең төп терәге дә, фикердәше дә булдылар.

Авылга асфальт юл илтә, табигате сокланып туймаслык, елга-күл буйлары, көрәш, җыр-бию мәйданчыгы, сәламәтләндерү-ял итү мәйданчыгы, Сөембикә манарасын хәтерләтүче мәһабәт корылма, музейлар комплексы һәм башкалар яшеллеккә төренгән, бихисап чыршы-нарат үзенә бер сихрилек өстәп тора, һавасы сулап туя алмаслык. Соңгы елларда гына да 600–700 гектар җиргә агач утыртылган. Булса да булыр икән шундый гүзәллек, үзенә тарту көче!

Миңгәр – халкыбызга СССР, РСФСР, ТАССРның халык артисты, Габдулла Тукай, Константин Станиславский исемендәге дәүләт премияләре лауреаты Шәүкәт абый Биктимеровны да биргән авыл әле ул. Халкыбыз күңелендә ул Әлмәндәр карт буларак мәңгелек урын алды. Миңгәрдә ул яшәгән йорт төзекләндерелгән, мемориаль такта беркетелгән, китапханәдә артистның иҗатын чагылдыручы музей булдырылган.

Җәүдәт Миңнәхмәтовның туган нигезендә нәселләренә мөнәсәбәтле музей да бик бай, авыл тормышы ачык күзаллана.

Ветеринария фәннәре докторы, профессор, Татарстан Дәүләт премиясе лауреаты Рәсилә Әхәт кызы Шәфыйкова – шулай ук Миңгәрнең, Татарстаныбызның горурлыгы.

Миңгәр дә, анда гомер итүчеләр дә үзгәргәннән-үзгәрә бара. Барысы да уңай якка. Әле шушы көннәрдә генә Татарстан районнарыннан, Киров өлкәсеннән, Башкортстан, Чуашстан республикаларыннан, Череповец һәм башка төбәкләрдән килгән кырыклап рәссам катнашында Бөтенроссия пленар-симпозиумы үтте. Рәссамнар ике атна дәвамында иҗатка чума. Якты, чиста, иркен бинада иҗат өчен барлык шартлар да тудырыла. Ашау-эчүләре тәмледән-тәмле, милли ризыкларга өстенлек бирелә. Ачык һавада йөрү өчен Кукмарадан киез итекләр дә алып кайтыла.

Миңгәрнең табигате, күренекле, истәлекле урыннары рәссамнар өчен иҗат чыганагы була. Кем белән генә әңгәмә корма: «Гаҗәп төбәк бу, тагын килергә язсын», – дигән фикердә. Ике атна эчендә йөзгә якын картина иҗат ителгән. Шуларның кырыкка якыны Миңгәр авылына бүләк итеп тапшырылды һәм озакламый рәсем сәнгате музеенда урын алачаклар.

Ел ярым элек Миңгәргә үзе дә рәссам, кинорежиссер Фәйзрахман Камалов кайтып төпләнгән. Кайткач, иске мәктәп бинасында остаханә ачып җибәргән. Аның бер өлешендә Фәйзрахманның туганы скульптура остасы, тел белгече Рушания Габидуллинаның кул эшләре булса, икенчесендә Фәйзрахман иҗат иткән сувенирлар, майлы буяу белән ясалган рәсемнәр һәм рәссамга төрле илләрнең осталары бүләк иткән сурәтләр. Монда Сөембикә, Үтәмеш Гәрәй сыннары да саклана. Остаханәсендә ул балаларга рәсемнәр ясаткан арада тарихка, яшәешкә мөнәсәбәтле табышмакларга җавап та таптыра, монысы инде халкыбызның үткәне һәм бүгенгесенә бәйле. Остаханәдә музыкаль кичәләр дә уздырыла, әле күптән түгел генә Биектаудан музыка уен кораллары ясау остасы Җәлил Вилданов килеп киткән. «Балаларның кызыксынуы да, соклануы да йөзләренә чыккан иде», – дип сөйләде Фәйзрахман Камал. Балаларны артыш агачыннан җәнлек сыннары ясау, күннән бизәнү әйберләре эшләү, чигү серләренә дә төшендергәннәр.

Рәссамнарны Миңгәргә иҗат сәфәренә килергә исә Татарстанның халык рәссамы Мөдәррис Минһаҗев илһамландырган. Ул – Саба төбәгендәге Шәмәрдән бистәсендә туып-үскән иҗатчы. Миңгәрнең иҗатка рухландыруына ул чын күңеленнән куана, иҗат өчен шартлар тудыручыларга чиксез рәхмәтләрен җиткерә, иҗат кешесенә ихтирам кимегән бу чорда рәссамнарның күңеленә илһам иңгән. Бу инде үзе үк бернигә тиңдәше булмаган халәт.

– Миңа рәссамнар иҗатына мөнәсәбәтле фикер җиткерелде, шуны гамәлгә ашырырга тырыштым. Фикердәшем исә мәгълүм шәхес – төпле фикерле, яхшы оештыручы, «Җыен» фонды әгъзасы Рәшит Ислахетдин улы Фәсхетдинов, – диде Җәүдәт Миңнәхмәтов. – Шәт, моның белән генә чикләнмәбез. Җәй көне табигатебез тагын да матуррак. Хәер, ел фасылларының һәрберсенең – үз матурлыгы. Уңган-булган авылдашларыбыз исә – озын да, җәен дә, көзен-кышын да осталарның остазы. Рәссамнарны ел дәвамында көтәбез.

Ахырдан рәссамнарны бүләкләү тантанасы булды. Иҗат әһелләрен Җәүдәт Миңнәхмәтов, Саба районы башкарма комитеты җитәкчесе Марат Ишниязов тәбрикләп, уңышлар теләделәр. Мул сыйлы өстәл әзерләнгән иде. Миңгәр сандугачы Рисәнә Мостафина моңлы, халыкчан җырлар белән иҗатчыларга канат өстәде. Һәркемнең күңеле шат, йөзе ачык иде. Рәссамнар Рисәнәгә кушылып җырладылар, берничәсе кулларына баян, гитара да алды. Кунакчыл Миңгәрдә башкача була да алмый инде ул.

Габделбәр РИЗВАНОВ

КОЛА ЯРЫМУТРАВЫ – СААМНАР ВАТАНЫ

Туган ил буйлап

Календарьдагы вакыйгаларны барлап утырганда күзем төште: февраль аенда Халыкара саамнар көнен дә билгеләп үтәләр икән. Соңгы вакытларда халык исәбен алу нәтиҗәләреннән алган тәэсирдәнме, аз санлы халыкларның язмышы бигрәк тә игътибарны җәлеп итә. Алда ни көтә, дип уйлана башлыйсың. Без Кола ярымутравына, саамнарның тарихи ватаннарына моннан ике ел элек барып чыккан идек. Дөрес, пандемия сәбәпле, күп нәрсәгә чикләүләр кертелгән иде ул вакытта. Әмма күргәннәр бүгенгедәй күз алдымда.

Саамнар

XI гасырда беренче христиан миссионерлары килгәнче, мәҗүсиләр булып, табигать кануннарына буйсынып яшәгән өчен, саамнарны шаманнар, күрәзәчеләр дип атаганнар. Әле хәзер дә аларда диңгез җанын юмалау өчен суга бакыр акча ыргыту гадәте яши икән. Чөнки аучылык һәм болан асрау белән беррәттән, балык тоту – аларның төп һөнәрләре. Дөрес, заманына күрә аларның да тормышы үзгәрә. «Яшел елан» гомерләрен кыскартуга бер сәбәп булса, кышкы көтүлекләрен тартып алганнан соң, боланчылык белән шөгыльләнү мөмкинлеге дә кими. Шулай итеп, җирле халык борын-борыннан килгән тормыш итү рәвешеннән мәхрүм кала. Яңа хакимият алып килгән яңача тормышка күнегергә теләмәүчеләрнең шактые егерменче-утызынчы елларда репрессия корбаны була. Икенче Бөтендөнья сугышыннан соң алар күпләп Норвегия, Швеция, Финляндиягә күчеп китәләр.

Хәзер Җир шарында 80 меңнән артык саам исәпләнсә, аларның 1500 тирәсе генә Мурманск өлкәсендә яшәп калган. Рәсми мәгълүматларга караганда, узган гасырның 90 нчы елларында ук аларның яртысыннан артыгы үз ана телендә сөйләшә алмаган. «Википедия»дә күрсәтелгәнчә, Швециядә Саам парламенты эшли, һәм анда саам теле, швед, фин телләре белән беррәттән, дәүләт теле булып тора. Саам халкы Төп халыкларның бөтендөнья советында дәүләт әгъзасы буларак теркәлгән.

Умба

Ярымутрауның күпчелек өлеше поляр сызык аръягына урнашкан. Ак диңгезгә чыгучы Кандалакша районына килеп керүгә, беренче тукталган урын Умба бистәсе булды. Монда яшәгән халык борын-борыннан, нигездә, балыкчылык белән шөгыльләнгән. Умба елгасы аша күпер салынган. Аның бер ягында – XV гасырда ук барлыкка килгән агач Помор авылы. Ул инде ярым җимерек хәлдә. Икенче якта – совет чорында төзелгән таш бистә. Аның

барлыкка килүе биредә урман кисү эшләренә бәйле. Кышын әзерләнгән нарат әрдәнәләрен язын сал белән дә агызганнар, транспортка да төяп җибәргәннәр. Элегрәк урман күбесенчә экспортка озатылган, соңга таба Россия ихтыяҗлары өчен дә киселгән. Шул чорда йортлар, мәктәп, хастаханә төзелгән, электр, радио, телефон элемтәләре килгән. Ул чакта бистәнең исеме дә үзгәргән: Лесной дип йөрткәннәр. Хәзер исә ул иске исеменә кайткан. Анда инде агач эшкәртү заводы да юк. Сирәк кенә вак таш җитештерү белән шөгыльләнәләр.

Диңгез суын кайнатып тоз җитештерү максатыннан, яр буендагы урманнарны да кисеп бетергәннәр. Яр буенда терлек көтүләренең күпләп йөрүе дә зыян салган, дип сөйлиләр. Чөнки җирнең өске катламында үсемлек заты калмагач, ком һәм җил һөҗүмгә күчкән. Шулай итеп, биредә Кузомень чүллеге барлыкка килгән. Якындагы авыл үзе дә шул исем белән атала. Хәзер инде монда яр буйлары ишелә, йортларның чоңгылга төшеп китү куркынычы да бик зур. Иң начары – уылдык чәчү өчен балык керә торган елга тамагы саега. Ә бу – төп шөгыле балык тоту булган халык эшсез дә, ашсыз да кала дигән сүз.

Немец борыны

Төп максатыбыз – Россиянең Европа материгындагы иң төньяк ноктасы – Немец борынына барып җитү иде. Димәк, без Средний һәм Рыбачий ярымутрауларына юл тотарга тиеш булабыз. СССР заманнарында бу ярымутраулар ябык хәлдә торып, анда хәрби базалар урнашкан була. Ярымутрау 2000 нче елларда ачылган. Контроль-тикшерү пунктында хәзер бары тик паспорт кына сорыйлар. Шулай да онлайн рәвештә Табигый байлыклар министрлыгы вәкилләрен кисәтеп куюны кирәк дип саныйлар.

Бу төбәкнең тарихы күп очракта хәрби операцияләр һәм бәрелешләргә бәйле. Рыбачий Бөек Ватан сугышы вакытында стратегик әһәмияткә ия була. Ярымутрауны саклап калу бөтен Кола ярымутравының, Мурманск шәһәре һәм аның туңмый торган портының иминлеген тәэмин итә, шуңа күрә Германия командалыгы әлеге җирләрне басып алуга зур көч ташлый. Средний ярымутравын материк белән тоташтыра торган Мустатунтури сырты аша фронтның төньяк сызыгы уза. Бу – немецлар фронт чиген өзә алмаган бердәнбер урын. Безнекеләр ярымутрауны өч ел ярым дәвамында үз кулларында тота. Монда нинди зур югалтулар булганлыгы хакында тарих битләрендә язып калдырылган. Бу җирләр кан белән сугарылган.

Ярымутрауда хәзер бистә-авыллар юк инде. Туристлар өчен берничә бәләкәй база гына төзелгән. Тау сыртының итәгендә Бөек Ватан сугышында һәлак булганнар истәлегенә мемориал куелган. Немец борынында бары тик бер маякчы хезмәт күрсәтә торган маяк, шуннан ерак түгел метеорологик станция һәм зур булмаган хәрби часть кына урнашкан.

Монда килгән туристлар, гадәттә, Териберкага да кагылмый калмыйлар. Баренц диңгезе буенда урнашкан бу бистә – илнең төньяк Европа өлешендә автомобиль юлы белән тоташкан бердәнбер торак пункт. Ул хәзер балык тоту һәм эшкәртүчеләр өчен сезонлы яшәү урыны буларак корылган. Бистәгә керүчеләрне ташландык кораб хәрабәләре каршы ала. Шуңа күрә дә аны «корабльләр каберлеге» дип йөртәләр икән. Ул саам җиренең җимерелеп, таралып бару символы кебек кабул ителә. Чыннан да шулай бит инде. Бу җирләрне балык тотып баерга килүчеләр берничек тә үз итмәс, мөгаен. Туристларны җәлеп итәр өчен оештырылган бутафорик Левоозеро авылы да җирле халыкның яшәп калуына берничек тә ярдәм итә алмас. Саам халкы әлегә бөтенләйгә юкка чыкмас үзе. Интернеттагы мәгълүматларга караганда, Скандинавия ярымутравындагы илләрдә аларга туган телне, гореф-гадәтләрне саклап калу өчен шартлар тудырылган. Ә менә безнең илдә, ни кызганыч, төрле милләт вәкилләре исәпкә алынган исемлек бик тиздән бер пунктка кыскарырга мөмкин.

Гүзәл ӘХМӘТҖАНОВА

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 5322 данә
Гомуми тираж – 15277 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 222

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кулъязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+